**Итоговая контрольная работа ( диктант с грамматическим заданием)**
**в рамках промежуточной аттестации**
**по родному (татарскому) языку для 7класса**

## Рус телендә белем бирүче мәктәпнең туган тел(татар теле) фәнен туган тел буларак өйрәнүче 7 нче сыйныф укучылары өчен арадаш аттестация өчен контроль диктант тексты.

Әнә шулай килә яз.

Кар сулары китеп бетте. Жир сарыкты, кипте. Тик урам уртасында гына ишегалларыннан ыргыткан соңгы боз кисәкләре эреп ята. Көннәр бик җылы тора, тиздән аларның да юеш эзләре калмас болай булгач.

Кабан инде боздан арчылган. Аңа хәзер Болак аша Идел суы керә. Ул тулып, күтәрелеп, гүя киерелә биреп ята. Яр битләрендә беренче тере яшь үлән дә баш төртеп чыгып килә. Карт тирәкләрне сырган бөреләр дә көннән-көн бүртә, сагызлана бара - тиздән, бәлки, нәни яфракларның очлары да күренә башлар. Ә аннары барысы да, гөлт итеп кабынгандай, ямь-яшел булып җилфердәшеп китәр берзаман!… Әнә шулай килә язлар, һичнигә карамыйча!… (Ә. Еникидән) (94 сүз)

**Бирем.**
1. Сыйфатларның астына сызыгыз, дәрәҗәләрен билгеләгез.
2. Җылы, яшь, карт, яшел сүзләреннән фигыль һәм исемнәр ясагыз.

### Контроль диктантларны бәяләү

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| 1. | Орфографик һәм пунктуацион хаталары булмаган эшкә<br>Искәрмә. Орфографик (яки пунктуацион) хаталы пөхтә башкарылган эшкә яки бер үк хата бер үк сүзләрдә кабатланса һәм бер пунктуацион хаталы эшкә | «5»ле билгесе куела.<br>«5» ле бил-гесе куела ала. |
| 2. | 1 орфографик, 1 пунктуацион хатасы булган эшкә<br>Искәрмә. 1 орфографик, 2 пунктуацион хаталы эшкә яки, орфографик хаталары булмыйча, 3 пунктуацион хатасы булган эшкә, яки бер төрдәге 2 орфографик һәм 1 пунктуацион хаталы эшкә | «4»ле билгесе куела.<br>«4»ле билгесе куела. |
| 3. | 2 орфографик, 1—3 пунктуацион хаталы, 2 төзәтүле эшкә<br>Искәрмә. 4 пунктуацион, 1 орфографик хаталы эшкә яки бер төрдәге 5 орфографик, 4 пунктуацион хаталы эшкә | «3»ле билгесе куела.<br>«3»ле билгесе куела. |

Электронный документ передан через оператора ЭДО ЗАО "ТаксНет" Вс, 01 дек 2024 14:04:41 МСК
Идентификатор документа a47d812b-18a8-42f8-b943-94ffd0cfa72a

| | | |
|---|---|---|
| 4. | 5 орфографик, 5 пунктуацион хаталы, 4 төзәтүле эшкә | «2»ле билгесе куела. |
| 5. | 6—7 орфографик, 4—5 пунктуацион хаталы, берничә төзәтүле эшкә | «1»ле билгесе куела. |

Әгәр грамматик бирем бер дә ялгышсыз башкарылса, «5»ле куела. Дүрттән өч өлеше дөрес башкарылмаган грамматик биремгә уңай билге куелмый.

ОТПРАВИТЕЛЬ
МБОУ "Средняя Общеобразовательная Школа №130 Имени Героя Российской Федерации Майора С.А.Ашихмина"
ПОДПИСАНО
ВЛАДЕЛЕЦ СЕРТИФИКАТА
Самаркина Ирина Николаевна
ДОЛЖНОСТЬ
Директор
СЕРТИФИКАТ
00991280801FAAF15BA3173E5BBA8F1E17
ПОДПИСАН
01.12.2024 14:04:28 МСК
ПОДПИСЬ ВЕРНА